КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 апрель г.Казань № 220

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июнь, 589 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 июнь, 589 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1318 нче, 2023 ел, 26 апрель, 528 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы

йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктның тугызынчы абзацына «мөһере белән» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада «М.У.» аббревиатурасын «М.У. (булганда)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы өченче - дүртенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин